РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» март 2020ел. г. Буинск 83 ИК-п номерлы

2019 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм күрсәтү буенча муниципаль программага үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 3 өлешенә, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 2 өлешенә, Буа муниципаль районы Уставына нигезләнеп , Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 06 июнендәге 254/ИК-п номерлы «2019 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүнең һәм яклауның муниципаль программасы» (22.01.2020 № 13/ИК-п номерлы карар редакциясендә) карары белән расланган «2019 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм итүнең муниципаль программасы»на (алга таба текст буенча - Муниципаль программа) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләр кертергә:

- муниципаль программаның 2 нче кушымтасыннан «Файдаланылмый торган күчемсез милек объектлары исемлеге» таблицасын төшереп калдырырга;

- 4.3 бүлегенең текст өлешенә, муниципаль программаның беренче бүлегеннән соң, түбәндәге редакциядә текст өстәргә:

«Буа муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан ярдәм итү Буа муниципаль районы муниципаль берәмлегенең мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан, өченче затлар хокукларыннан ирекле муниципаль мөлкәтнең (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) расланган исемлекләренә (алга таба - Исемлек) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон (27.12.2019 елның 27 декабрендәге редакциясендә) нигезләмәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Буа муниципаль районы муниципаль берәмлегенең милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы әлеге программаның бурычлары һәм максатлары нигезендә, шулай ук “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон (27.12.2019 еллар редакциясендә) нигезләмәләренә ярашлы рәвештә түбәндәге чаралар исемлегенә карата үтәлүне тәэмин итә:

1) Буа муниципаль районының һәм аның составына керүче җирлекләрнең муниципаль мөлкәте санын кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән тиешле исемлекләрдә арттыру;

2) Исемлеккә кертелә торган мөлкәт составын киңәйтү, аның сыйфатын яхшырту;

3) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына исемлектән шартнамәләр нигезендә озак вакытка биләүгә (файдалануга) бирелә торган мөлкәт санын арттыру;

4) әлеге программа һәм муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары - милекчеләр карарлары нигезендә гамәлгә ашырыла торган мөлкәтне арендага бирүнең ташламалы тәртибен камилләштерү;

5) мөлкәтне биләүгә (файдалануга) бирү процедураларының үтә күренмәлелеген гадиләштерү һәм арттыру.».

- 4.3 бүлегенең таблица өлешендә, муниципаль программаның беренче баганасында 2 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә таянып, муниципаль мөлкәтнең расланган исемлекләренә кертелгән күчемсез һәм күчемле мөлкәтне бүлеп бирү юлы белән күрсәтелә.

- муниципаль программаның V бүлегендә дүртенче абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Буа муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан ярдәм итү Буа муниципаль районы муниципаль берәмлегенең мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан, өченче затлар хокукларыннан ирекле муниципаль мөлкәтнең (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) расланган исемлекләренә (алга таба - Исемлек) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон (27.12.2019 елның 27 декабрендәге редакциясендә) нигезләмәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.».

- «2019-2023 елларга Буа муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча төп индикаторлар » муниципаль программасының 1 нче кушымтасында 10 пунктны «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү буенча максатчан күрсәткечләр» түбәндәге редакциядә өстәргә:

| т/н | Күрсәткечләрнең аталышы | Үлчәү берәмлеге | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 10 | Муниципаль мөлкәт исемлекләрендә мөлкәт объектлары санының ел саен кимендә 10 %ка артуы | берәмлек | 5 | 13 | 15 | 17 | 19 | 21 |

2. Әлеге карар имза салынган көненнән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән басылып чыгарга, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе Р.Р. Камартдинов